КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 сентябрь г.Казань № 793

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1370 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1194 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы; 2024 ел, 7 май, 311 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Профилактик чаралар үткәрү турындагы карарларны Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы, Министрлыкның территориаль идарәләре башлыклары – Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге урынбасарлары кабул итә.

Контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турындагы карарларны Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы кабул итә.»;

1.6 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны I, II, III, IV категорияләр объектларына кертү критерийларын раслау турында» 2020 елның 31 декабрендәге

2398 номерлы карары белән расланган критерийлар» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны I, II, III, IV категорияләр объектларына кертү критерийларын раслау турында» 2020 елның 31 декабрендәге 2398 номерлы карары белән расланган әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны I, II, III, IV категорияләр объектларына кертү критерийлары (алга таба – Критерийлар)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан кулланыла, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган җитештерү объектлары билгеле бер риск категориясенә кертеп карала:

а) урта дәрәҗәдәге риск категориясенә төбәк дәүләт экология контроленең (күзәтчелегенең) әйләнә-тирә мохиткә уртача тискәре йогынты ясый торган объектларны Критерийлар нигезендә II категория обектларына кертү критерийларына туры килә торган объектлар (комплекслы экологик рөхсәт бирелгән һәм федераль дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле объектлардан тыш) кертеп карала;

б) уртача дәрәҗәдәге риск категориясенә төбәк дәүләт экология контроленең (күзәтчелегенең) әйләнә-тирә мохиткә шактый булмаган тискәре йогынты ясый торган объектларны Критерийлар нигезендә III категория обектларына кертү критерийларына туры килә торган объектлар кертеп карала;

в) түбән дәрәҗәдәге риск категориясенә төбәк дәүләт экология контроленең (күзәтчелегенең) әйләнә-тирә мохиткә минималь тискәре йогынты ясый торган объектларны Критерийлар нигезендә IV категория обектларына кертү критерийларына туры килә торган объектлар кертеп карала.

Төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелек) объектлары өчен риск категориясен исәпләп чыгару әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны исәпкә ала торган программа-техник тәэминаты ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар, Министрлыкка тиешле рәсми сорау җибәреп, бирелгән риск категориясе турында мәгълүмат алырга мөмкин. Юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны һәм алар тарафыннан файдаланыла торган җитештерү объектларын билгеле бер риск категорияләренә кертеп карау турындагы мәгълүматка, үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләреннән чыгып, үзгәреш кертелергә мөмкин.

Әгәр төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объекты су объектларының су саклау зоналарында яки аларның өлешләрендә урнашса, әлеге пунктның «а», «б» пунктчалары нигезендә урта, уртача дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиешле төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектлары шул ук эзлеклелектә шактый, урта дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиеш.

Югары, шактый, урта дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиешле төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектлары, ачыкланган, тикшерү нәтиҗәләре белән расланган мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләнгән срокта бетерелгәннән соң, шул ук эзлеклелектә шактый, урта, уртача дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.1^1$ пункт өстәргә:

«2.1[1]. Шактый, урта, уртача дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиешле төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектлары, төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектын риск категорияләренә кертү турында суд карары кабул ителгән датага кадәр өч ел эчендә үз көченә кергән түбәндәгеләр булганда, шул ук эзлеклелектә югары, шактый, урта дәрәҗәдәге риск категорияләренә кертелергә тиеш:

а) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.3, 7.4, 7.6, 8.2, 8.4, 8.6, 8.7, 8.9 статьяларында, 8.10 статьясындагы 1 өлешендә, 8.11, 8.12, 8.13, 8.14, 8.21, 8.32, 8.42, 8.44, 8.45, 14.1 һәм 19.20 статьяларында каралган һәм эшчәнлекне төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектыннан файдаланып гамәлгә ашырганда кылынган административ хокук бозуны кылган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яисә индивидуаль эшкуарга Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан төзелгән административ хокук бозу турындагы беркетмә нигезендә вазыйфаи затлар (әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары) яисә суд тарафыннан чыгарылган административ җәза (кисәтү рәвешендә административ җәзадан тыш) билгеләү турында карар;

б) төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектын файдаланып, хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы вазыйфаи затны, юридик затны яисә индивидуаль эшкуарны Россия Федерациясе Җинаять кодексының 246, 247, 250 – 255 һәм 257 статьяларында каралган җинаять кылуда гаепле дип тану карала торган судның гаепләү хөкеме;

в) төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) объектын файдаланып, эшчәнлек башкарганда шундый зыян салуга китергән административ хокук бозу кылган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки индивидуаль эшкуарга административ җәза билгеләү турында карар.»;

VI бүлекнең беренче абзацында «контроль-күзәтчелек эшчәнлеге» сүзләрен «контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар (әлеге карарның 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пунктындагы алтынчы – унсигезенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин